ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» декабря 2023 ел № 398

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасының 19.12.2006 елның 80-ТРЗ номерлы Кодексына таянып, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакындагы«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»21.07.2023 елның 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына үзгәреш кертергә, аны әлеге карарга кушымта итеп бирелгән редакциядә текст белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 05.07.2023 елның 193
номерлы карарына кушымта
(карар редакциясендә 25.12.2023елның
398 номерлы)

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына өстәмәләр**

| ТР КоАП маддәләре | Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге | Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турындагы эшләрне ведомство карамагындагы хокук бозулар буенча карарга вәкаләтле органнар |
|---|---|---|
| **3.10 маддә.**<br>Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен (гражданнарга карата) бозу | - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең әйдәп баручы белгечләре<br>- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы әйдәүче белгече | Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча 1, 2 нче суд участокларының җәмәгать судьялары (7.1 статья). ТР Административ хокук бозулар кодексы) |